КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 5 декабрь г.Казань № 1287

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кытай Халык Республикасындагы сәүдә-икътисад вәкиллеген гамәлгә кую турында» 2014 ел, 1 октябрь, 707 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кытай Халык Республикасындагы сәүдә-икътисад вәкиллеген гамәлгә кую турында» 2014 ел, 1 октябрь, 707 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 15 май, 401 нче, 2019 ел, 29 май, 451 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Кытай Халык Республикасындагы сәүдә-икътисад вәкиллеге турында нигезләмәнең 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Вәкиллекне үз вазыйфасына өч елга билгеләнгән һәм вазыйфасыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан азат ителә торган Сәүдә-икътисадый вәкил җитәкли.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин